ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ ИЮЛЬ * 2020 * КАЗАН

7





Равил ФӘЙЗУЛЛИН

ХӘЛЕҢ НИЧЕК, АВЫЛ?

Әй, авыл, син мең шәһәрдән
мең кабат ямьле вә хуш.
С. Рәмиев

Хәлең ничек, авыл?

Хәлне әйтә табын!
Савым,
артым,
җыем...
Җыем, артым, савым...
Мал-каралтың – илең,
тирес түгәр җирең,
маңгаеңда – тирең...
Төшкән тешләр кебек
йортлар кимеп бара.
Беренче сыйныфта
быел ике бала...

Хәлең ничек, авыл?

Ару гына болай...
Өйләрдә газ яна.
Абзарда юк маллар.
Телевизор ачсаң –
яңа сериаллар.
Онытылды күптән
китап укыганнар...
Өйләнмәгән буйдак
ир-ат урам тулы.
Кызларның уенда
шәһәр-кала юлы.

Хәлең ничек, авыл?


Түгел зарланырлык,
өс бөтен, тамак тук.
Дөрес, акча бик юк...
Бетмәс, ахры, бездә
крепостнойлык...

...Тыкрык чатында
әйтте ялгыз түтәй:
"Авыл – кабыгы сау,
эче аккан күкәй..."

Хәлең ничек, авыл?
Әлхәмдүлиллаһ, шөкер.
Аулак өйләр җыры,
тальяннар моңы
онытылды дисәм,
бәгыреңә тисәм –
кичер мине, дустым! –
авыл болай исән!
Сулар һава һәйбәт,
Сабантуйлар исән.

Буласылар булган,
кибәселәр кипкән...
Туган нигезләрдә
көлләр эреп беткән...
Безнең күбебезне
авыл кеше иткән!

...Буш мәчетләр өсләп
азан ишетелә.



Сергей АНДРИАНОВ



ШОМБАЙ
болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Бу яңа вирус пандемиясе кешеләр өстеннән күзәтү урнаштырырга хыялланучылар өчен бүләк булды. Электрон пропусклар, QR-кодлар, масканы бар дип тә белми торган кеше йөзен тану системалары... Боларның барысы да безнең сәламәтлекне саклау максаты белән эшләнә, әлбәттә. Тик, нишләптер, бу күзәтү чаралары вирусны җиңгәч тә калыр кебек тоела...

Л. САФИУЛЛИН

КАЗАН

Укучының хатын без мөгтәбәр Шомбай агабызга күрсәттек.

– Шунысы кызык, – диде аксакал, **– ә кайчан да булса ришвәтче чиновникларны һәм алар урлаган мал-мөлкәтнең кая китүен күзәтә торган камералар куярлар микән?**

Валерий ТАРАСЕНКО



Ринат АБЗАЛОВ

ИЮНЬ МАНЗАРАСЫ

Эңгер-меңгер кочып ала җирне
Ашыкмыйча, сиздерми генә.
Йолдызларның сыек җемелдәве
Җәйрәп китә июнь күгенә.
Бер сәгатьлек йолдыз дөньясына
Сокланырга тизрәк өлгер син –
Уй-теләкләр, йөрткән хыялларың
Күккә ирешергә өлгерсен.

Ә кояшка нәрсә? Тиеш эшен
Бик житез һәм оста башкара;
Чумып кына чыга ул офыкка –
Үз вакытын бирми башкага!
Һәм яңадан җылы нурын сибеп,
Иркен күкне иңләп әйләнә;
Кичен кыска сменаны бирә
Күкне баскан зәңгәр сәйләнгә.

• • •

Яңа гына институт бетереп эшли башлаган чибәр кыз баш табибка зарлана:

– Иелеп, авыру ир-атларның пульсларын үлчи башласам, аларның йөрәкләре ешрак тибә башлый. Бу нидән икән?

– Ә син, сеңлем, йә аларның күзләрен бәйлә, йә күлмәгеңнең өске төймәләрен каптыр.

Александр ШУЛЬПИНОВ



БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Дәһшәтле яңа вируска "корона" дигән дәрәҗәле сүзне чәпәп куйдылар! Миңа калса, воронавирус та бик таман булыр иде әле...

Алмаз Хәмзин: Алайса, шул ук Кош гриппы була бит инде ул.

Р. Н.: Татарстаннан ага торган "Дружба" газүткәргеченең өч тиенлек тә файдасын күрмәдек.

А. Х.: Гәрчә, күне-төне янып торган газ факелларыннан республикабыз күге балкып торды.

Р. Н.: Беркөнне Александр Безпутин дигән боксчы көндәшен җиңде. Шундый фамилия белән аны ничек рингка кертләр икән, дим...

А. Х.: Күренеп тора бит инде – Путин белән булмаганга. Путин белән булса, кермичә дә җиңәр иде.

Р. Н.: Кремльдә сәяси "фокусник"лар күбәйде – туган телне "ә" дигәнче юкка чыгаралар!

А. Х.: Болай кылансалар, алар телне генә түгел, туган илне югалтуга да күп вакыт сорамаслар.

Р. Н.: Аркасы белән җылы кәнәфигә чумдымы, бу кешедән баш бирмәс түрәлек һәм... Мәскәүдән курку, аларга куштанлану башлана.

А. Х.: Рашат дус, моны язмасаң да, бу мәгълүм хәл...

Р. Н.: Идел елгасы үзенең Каспий диңгезенә барып житәчәген белә микән?

А. Х.: Белә. Ләкин Каспийның банкротка чыга баруын белми. Безнең җәмгыять шикелле инде...

Р. Н.: Баллы, рәхәт, тук тормышта яшәүче олигархтан фәлсәфә һәм ачышлар көтмә.

А. Х.: Кая инде көтү, ул бит бездәй кешенең бар икәнен дә белми.

Р. Н.: Мәхәббәтнең 50 проценты оптимизмнан тора, калганы?..

А. Х.: Калганы үзеңнән.

Р. Н.: Өй телефоны кайчагында кесә телефонын эзләп табарга ярдәм итә!

А. Х.: Шулай гына шул...

Беркемгә дә сер түгел – эштә иминлек техникасына еш кына ниндидер кирәк булмаган, эш вакытын ала торган әйбер дип карыйлар. Имеш, үзебез дә бала-чага түгел – башка кирпеч төшүнең һәм станокта бармак кисерүнең нәрсә икәнен беләбез. Ә кайчак онытылып китсәң, иңдә фәрештәләр утыра бит. Ләкин кырыс тормыш көтмәгәндә башкача борып куя икән шул...



Менә күптән түгел Казанда газ бүлү станциясендәге шартлау бөтен каланы тетрәндерде. Янгын сүндерүдә ике йөзләп кеше һәм 58 данә техника эшләде. Кызганыч, зыян күрүчеләр дә булды... Эш көненең гадәти тәртибен шундый хәвефле рәвештә нәрсә бозгандыр – моның сәбәбен тикшерү ачыклар. Тик инде хәзер үк иминлек кагыйдәләре үтәлмәгән дигән фараз бар. Әйтергә кирәк, узган ел әчендә генә эре предприятиеләрдә 14 янгын очрагы булган. һәм бөтенесендә дә бер үк сәбәп – иминлек техникасы кагыйдәләрен бозу.

Хәвефлелек дәрәҗәсе буенча, промышленность өлкәсеннән соң төзелеш бара. Бу аңлашыла да. Төзелеш бөтен җирдә гөрләп тора, квалификацияле эшчеләр аз, күбрәк инструктажларда сүзнең нәрсә турында барганын да аңламаучы "кунаклар" эшли. Моның нинди нәтиҗәләргә китерүен үзегез карагыз.

Казанның Ершов урамында биш эшче белән басма өзелеп төшкән. Ике бичара шунда ук җанын фида кылган, калганнарын хастаханәгә алып киткәннәр. Габишев урамында унөченче каттан эшче егылып төшкән. Аны коткара алмаганнар. Ә Зорге урамында дүртенче катта эшләгәндә профессия остасы – альпинистның тросы өзелгән. Аста аны саклап торучы иптәше "бер минутка гына" китеп барган булган. Өстә эшләүченең умыртка сөяге сынган.

Әйтергә кирәк, бу хәлгә кешеләр генә түгел, төзелеш краннары да дучар булгалый. Узган ел "Салават күпере" торак комплексы төзелешендә шундый хәл булган. Бәхеткә, монда барысы да исән калган. Бу очракта гаепне техника астындагы грунтны какшаткан көчле яңгырга сылтаганнар...

Ә авыл хуҗалыгыгда хезмәт иминлеге белән эшләр ничек тора? Комбайнёрлар, тракторчылар һәм башка механизаторлар ничек эшли? Баксаң, хезмәт техникасы инструкцияләре аларга гына кирәк түгел икән. Апас районында бер терлекче күңелсез хәлгә дучар булган. Кагыйдә буенча, арбага утырып барырга тиеш булуга карамастан, ул җигелгән ат белән янәшә барган. Ат кинәт чабып киткән, ә абзый тояк астына эләккән. Ә менә Биектау районында яшәүче хатынны аның җиренә адашып кергән фермер үгезе сөзеп үтергән. Мөгезле терлекнең көтү кагыйдәләрен бозган хуҗасын судка биргәннәр...

Бу материалларны җыйганда миңа Чаллыда төзелеш фирмасында эшләүче иминлек техникасы инженеры Ильяс Л. белән очрашырга туры килде.

– Безнең эшне җитди кабул итмиләр, – диде ул. – Бәйләнчек чебенгә караган кебек карыйлар. Ә ул-бу була калса – бөтен гаеп сиңа... Шуңа күрә каскасыз йөргән гамьсезләргә берөзлексез тукыйм: "Хезмәт техникасы иминлеге ул – дин кебек..."

– Моны ничек аңларга? – дип сорадым мин.

– Ышану-ышанмау – үз эшең, ә кагыйдәләрне, гореф-гадәтләр кебек, үтәү хәерлерәк...

Людмила САФИУЛЛИНА



Эльвира ДЫШАЕВА



Ринат АБЗАЛОВ



Валентин ДРУЖИНИН





• • •

Безнең барлык байлыгыбыз эчебездә. Бөерләребез генә дә ни тора!

• • •

Бала тудыру йортында шәфкать туташы ата кешегә өч игезәк алып чыга. Бераз уйланып торганнан соң ул әйтеп куя:

– Каршы булмасагыз, мин уртадагысын алыр идем...

• • •

– Әйдә әле, чибәркәй, бер җил үртәп әйләнеп килик?

– Юк, юу-у-к, миндә ревматизм.

– Алайса мунчага – рәхәтләнеп чабынып кайтырбыз!

– Миңа ярамый, йөрәгем кадап тора...

– Нигә соң, шулкадәр авыру булгач, күз уйнатып маташтың?

– Кылый бит мин...

• • •

Таҗлы вирус чоры – җинаять эшләү өчен иң кулай вакыт. Бите күренми, бармак эзләре калмый, өстәвенә, битлек һәм перчатк, кигән кеше беркемдә дә шик тудырмый.

• • •

Карантинның икенче этабында балаларга урамда куышлы уйнау рөхсәт ителде. Өченче этапта куып җитеп тотарга рөхсәт итәчәкләр.

• • •

Кабул итү бүлмәсендә.

– Туташ, миңа сезнең директорыгыз белән сөйләшеп алырга кирәк иде.

– Кызганычка каршы, ул кичә генә вафат булды.

– Миңа бит ике минутка гына!

• • •

– Кактус тискәре энергияне җыя икән бит.

– Әйе, өстенә ялгыш утырсаң бигрәк тә.

• • •

– Син миңа өч мең сум бирәсеңне онытмадыңмы?

– Син, нәрсә?! Соңгы минутымда да онытмаячакмын!

• • •

Медицина, безнең бистәне артта калдырып, бик алга китте.

Екатерина СЕМЁНОВА



Юрий КУХАРЕНКО



Александр КОСМЫЛИН





ХОКУК САКЛАУЧЫ ҖИНАЯТЬЧЕЛӘР

Яшел Үзән районында оперативниклар махсус урында яшерелгән наркотикларны алган чакта ике бәндәне тоткарлаганнар. Дусларның бик гади булмаганнары ачыкланган. Беренчесе, Айдар Хәлиуллин, үзенә кагылырга ярамау турында белдереп, Яңа Савин районының мировой судья таныклыгын күрсәткән. Икенчесе, Фәрхәд Сафиуллин, дәрәҗәсе буенча түбәнрәк – Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәре булып чыккан. Изоляторга икенчесен генә япканнар, судьяны башта эшеннән чыгарганнар. Аларның җинаять юлына басуының сәбәбе: азартлы уеннар уйнап бурычка батулары икән.

ЯЛКАУ БЕЛГЕЧ

Казандагы Киров һәм Мәскәү районнарының җәмгыять иминлеге мәсьәләләре бүлегенең баш белгече үз вазыйфаларын башкарып мәшәкатьләнмәгән. Үзенә беркетелгән территорияне тикшереп торып, законсыз сәүдәгә юл куймаска тиешле чиновник бүлмәсеннән чыкмыйча гына беркетмәләр тутырып утырган. Штрафка тартылганнарның берсе ит сатучы булып чыккан. Эшмәкәргә 65 мең сумлык утыз штраф билгеләгәннәр. Ул тикшерүчене күрмәгән дә, ә үзенең "кагыйдә бозуы" турында Интернет порталыннан белгән.

КАРТ СТУДЕНТЛАР

Чүпрәле тармак технологияләре техникумы директоры белем бирү өлкәсендә студентлары белән генә чикләнеп калмаган. Бюджет чыгымнарын тикшерү вакытында белем алучылар арасында директорның үзенең, аның урынбасарларының, берничә укытучы һәм аларның туганнарының исемнәре табылган. Бу "уку"ны җитәкчелек өч ел буе алып барган, ә "студентлар" стипендия алып килгән. Моның өчен директор эшеннән азат ителгән.

КӘГАЗЬ РЕМОНТ

Лениногорск Үзәк район хастаханәсе 25 миллион сумлык ремонттан соң нәни пациентларны кабул итә алмаган. Кәгазьдә капиталь ремонт проект буенча, вакытында башкарылган һәм таләп ителгән шартларга җавап биргән, ә чынбарлыкта медицина хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудырылмаган. Акчаның кая китүен хәзер тикшерү органнары ачыклый.











Илдар НӘФИЕВ рәсемнәре.

Абау!

ОЧРАШУЛАР

Уфаның өченче төзәтү колониясенең нәчалнигe очрашулар оештыруда тотылган. Ул ике ел буе туганнарының тоткыннар белән күрешү мөмкинлеге белән сату иткән. Күрешүнең бәясе 15 меңнән 110 меңгә хәтле булган. Түләүле хезмәттән баш тарту ярамаган эш булып саналган, түрә, утыручыга үч итеп, яшәү кагыйдәләрен бозган өчен яңа җәза белән янаган. Суд очрашулар сатучыны 3,5 елга төзәтү колониясенә җибәргән, ләкин тоткын сыйфатында.

СКАЙП БУЕНЧА МУНЧА

Ярославль өлкәсендә мунчалар һәм сауналарга эшләргә рөхсәт иткәннәр. Тик бер шарт белән – юынучылар онлайн гына булырга тиеш. Аптыраган эшмәкәрләр региональ түрәләрдән аңлатма сораганнар, тик җавап итеп постановлениедән өзекне ишеткәннәр. Мунча хуҗалары хәзер яңа эш шартлары буенча социаль челтәрләрдә коллегиаль рәвештә фикер алышырга мәҗбүрләр. Алар кемдә дә булса мондый тәҗрибәнең булу-булмавы һәм онлайн-юынуда мөмкин катлаулыклар белән кызыксыналар.

КОСМИК СТАНДАРТ

Роскосмос космик темага багышланган лифтлар җитештерә башлаячак. Алар күзге, музыка, тавышлы һәм язма информацияле күп төсле дисплей белән җиһазландырылган булачак. Кергән пассажирларны лифт данлыклы "Киттек!" дигән сүз белән каршы алачак. Лифт алай-болай туктап калса, нинди сүз әйтеләчәге әлегә билгесез.

ШПИОН КҮГӘРЧЕН

Һиндстанда өч ел төрмәдә утырган күгәрченне ирекка чыгарганнар. Кошның гаебе аягына ниндидер саннар язылган кәгазь бәйләгән килеш Һиндстан белән Пакстан чиген кисеп үтүдән гыйбарәт булган. Хакимият фикеренчә, бу – шпион хәбәре. Хуҗасы аңлатуынча, бу гап-гади почта күгәрчене, ул кошлар ярышында катнашканда ялгыш күрше дәүләтнең территориясенә очып кергән. "Элемтә"не читлеккә ябып куйганнар. Иреккә чыккан кошның кая очып киткәне билгесез.




Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Валерий ТАРАСЕНКО



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ



• • •

Яшь ир белән хатын чирләп китә. Икесенең дә авырулары бертөсле. Киңәшләшкәннән соң, вакыт һәм акча әрәм булмасын дип, табибка беребез генә барабыз дигән карарга киләләр. Ире *хатынын каршы ала:*

– Йә, табиб бездә нәрсә тапты?

– Котлыйм сине, без икебез дә авырга узганбыз, – ди хатыны.



• • •

Бер Казан газетасының баш мөхәррире хезмәткәрләрен җыйган:

– Шул «җирле» сүзен күпме файдаланырга була инде? Җирле яңалыклар, җирле хакимият... Шәһәр исемен күрсәтеп булмыймыни?

Икенче көнне, ул газетасында мондый юллар укыган: «Аварияга эләккән кешегә хастаханәдә Казан наркозы белән операция ясаганнар».

• • •

– Сезгә инде операция ясадылармы? – дип сорый баш табиб авырудан.

– Әйе.

– Йә, ничек?

– Биш мең сум.

– Сездә нәрсә иде дип сорыйм.

– Миндә бер мең генә иде.

– Тагын аңламадыгыз. Нинди зарыгыз бар иде дип кызыксынам.

– Акчаны күп каералар...





Алмаз ХӘМЗИН



(Булырга мөмкин хәл)

Нишләргә дә белми инде Нәсимәтти бердәнбер улы Миллер белән... Өйләнми бит... Эчүен дә ташлатасы иде... Әтисе кушты аңа шундый исем, теге "газ" хуҗасы – олигарх кебек зур бай кеше итеп күрәсе килгәндер инде улын. Күрәсе килү генә аз шул – тәрбияли белергә дә кирәк. "Аңа тагын... – дип үзалдына мыгырдап куйды ул, моннан ун ел элек җан тәслим кылган ирен уйлап. – Көне-төне эчтеләр... Үзе җыйган трактор, комбайн белән сукалады, чәчте, урды. Дуслары: Җәмил, Сәүбән дә шундыйлар иде. Барлык авыл эше алар җилкәсендә булды, – дип көрсенеп тә алды, шуларны яхшы яктан искә төшереп. – Эчтеләр шул, эчтеләр... Хәер, ул заманда кем эчмәде дә, кем... урламады. Болар – эштә, хәйләкәрләр – бурлыкта иделәр. Аның бит ул вакыттагы Илбашы да айнымас алкаш иде, – дип, ирләрнең гаебен киметкәндәй кыяфәт кертте йөзенә. Җәмил белән Сәүбәннең тол калган Дөрия һәм Хәтимәсен дә жәлләп куйды бер очтан. – Өчесе тиң аракыдан агуланып, безне ялгыз калдырып китеп барсыннар инде... Ничек моңа йөрәк түзсен!.. Бу баланы ничекләр тәрбияләп, башлыкүзле итәргә? Сердәшләремнекеләрдә дә өмет юк. Алар зуррак булып, Себер якларында эшләп көн күрсәләр дә – ялгызлар. Менә инде үз малаем да студент – соңгы курсы. Ничек укытып чыгарырга моны? Пенсия генә җитми бит".

Нәсимәтти бераз елап алды... Җитмәсә, илгә афәт килгән – коронавирус. Халыкны кыра. "Хәер, авылда моннан үлгән кеше юк әле – эчеп күбрәк китәләр. Ничава, җиңәрбез!" – дип батыраеп куйды ул.

Шундый гадәти уйлар белән яшәп ятканда авылга Дөриянең улы Җәмил Себереннән шул куркыныч чирне эләктереп кайтканлыгы мәгълүм булды. Шулдырмы, түгелдерме – халык һич шикләнүсез шуңа юрады. Инде бүлнистә ике атна ятып чыкканы да ачыкланды. Чирләгәндә бер медсестра белән танышканлыгы да ишетелде. Әйе, йөзен-битен күрүен күрмәгән икән, ләкин Җәмилнең сөйләве буенча, бик чибәр ди. Чибәрлекне бит аны яшерә алмыйсың, гәрчә ул медсестралар водолазныкы кебек киемдә йөрсәләр дә. Терелеп беткәч, өйләнешергә сүз бирешкәннәр. Коронавирустан дәвалану бер очтан сәрхушлеген дә бетергән моның. Җәмил хәзер чип-чиста ди.

Авыл халкы бу хәлгә шаклар катып калды. Нәсимәтти дә хәйраннар булып өендә, нишләргә белмичә, Җәмилгә сокланып, аның әнисе өчен сөенеп, бераз көнләшебрәк тә йөрде. "Башларымның ни уйларга белми торган чаклары" дигән җыр теленнән төшми башлады. Аның уй очында ниндидер өмет кабынды, ләкин нинди ул – әле белерлек түгел...

Бәхетенә, Хәтимәнең малае Галинең дә шушы коронавирусны эләктерү аркасында, бизнесы "көеп", авылга, әнисенең пенсиясе янына кайтуы билгеле булды. Бизнесы дип әйтүе сәбәп кенә инде – эләктергән бу әлеге чирне – температура, ютәл... Эчәргә акчасы да беткәндер... Авыл фельдшеры Нажия моны район "скорые"н чакыртып үзәккә озатканда Нәсимәттине Гали кочагыннан көчкә аерып алдылар. Авыруны тиз арада җибәрергә кирәк, ә бу һаман сердәшенең улы куенында. Елый да елый, нәрсә булгандыр?.. Сере бар иде кыланмышының... Әлеге дә баягы – үзе аңлап бетермәгән хәйләсе...

Китте Гали. Хәбәрләр килеп тора. Бик яхшы дәвалыйлар икән. Бу да бер медичка кыз белән танышкан, ди. Исеме – Наташа. Әй, кем булса да барыбер түгелмени?.. Үгез булмый – чурт булсын, балаларга сөт булсын дигәндәй... Менә кайтып та килделәр. Медичкасын да ияртткән. Һаман водолаз киеме белән – салмыйлар – карантин бетмәгән. Әллә ничек – бар бит яшел алагаем зур гөберле бака – шуңа охшап куя кайчакта киленкәй кеше. Шул: "Өйләнермен инде, әни!" – дигәне генә аермачык ишетелә Нәсимәттигә дә. Көнләштерәләр. Хәтимәгә рәхәт тә бит... Җитмәсә, Гали эчүен ташлаган. Ул да: "Таҗлы вирус уколларының ярдәме тиде", – ди. Нәсимәттигә шунысы әһәмиятле иде шул. Шуңа кочаклады ул Галине билен сындырырдай итеп – ягъни чире яхшырак сеңсен дип бүлнискә озатканда. Ашыкмагыз, соңгы теләге үтәлү-үтәлмәвен белергә!..

Шундук авылга Галинең терелеп, айнып, өйләнеп кайтуын төшерергә шәһәрдән телевидение килеп төште. Әй, чарт-чорт камераларының төймәләренә басалар, аллап-артлап, ятып, баскычлар куеп өстән, яннан... Сөйләштерәләр... Сенсация, сенсация! Гомер булмаган шаккаткыч хәл! Экраннарда кич, иртән, көндез шуны күрсәтәләр. Яңалык бөтен җир шарын урап алды.

Нәсимәттинең улы Миллер белән дә булачак бит әле мондый могҗиза!

Шулай уйлап, әле генә институттагы укуларыннан тукталып кайткан улын ишек төбендә үк үбәргә, кочарга тотынды ул. Булсын, булсын, эчкән булсын, махмыры аңкып торсын! Газизе кайткан бит, күз нуры, бердәнбере!.. Ярый әле улының институттан куылырга тиешлеген белми Ана... Шушы "сәрхушлеге өчен, бирелмәгән имтиханнары өчен. Рәхмәт Таҗлы Вируска! Коткарды, кичерде гөнаһларны, бурычларны киләсе елга да бирергә була. "Бар бит Ул Аллаһы Тәгалә!" – дип эчкән иде Миллер соңгы шешәсен вирус хөрмәтенә. Бөтен эче тутырык кайнаганын сизә егет аның барлыгын. Әнисе дә эченнән: "Хәзер төзәтәбез аны, чирләтәбез, бүлнискә җибәрәбез! – дип өтәләнеп йөри улын сәрхушлектән коткару өчен нишләргә белмичә. – Пускай чирләсен, аракы эчеп күбрәк кырылалар әле, монысы белән чуртым да булмас! Үзенә Галинеке, Җәмилнеке шикелле тормыш иптәше ияртеп кайтыр!

Миллерның әнисе халәтенә керердәй хәле юк иде бу чакта. Ул урынга тәгәрәде. Аңа карап Нәсимәтти дә: "И Аллам, туры юллар күрсәт шушы балага, өйләнеп балаларын тәрбияләргә язсын, сөеп туялмас идем оныкларымны", – дип йокларга күзен йомды.

Төнлә уянып, караватында улының юклыгын күрде дә, шиккә төшеп, ишегалдына чыкты. Баскыч төбендә утыра икән.

– Йоклый алмыйсың мәллә, балам? – диде аңа беренче сүзен җайлап.

– Баш әйләнә, әни, йөткерәм...

– Салкын тиде микән?

– Миңа каян тисен ул?

– Тирләп кайтып кердең бит кичә!

– Пахмельдән анысы...

– Фельдшерны чакыртыйк, әйтер.

– Балага узарга мин хатын кеше түгел, әни, – дип шаярткан булды Миллер. Әмма хәле бер дә шаяртырлыкка тартмый. Укшый ук башлады.

Нәсимәтти улының маңгаен тотып карады.



– Жар бит синдә, улым! – диде дә, каядыр йөгерде. Фельдшер Нажиягәдер...

Төн булса да, Нажия инде белгән кебек, каршыга ук килә.

– Миллермы? – ди.

– Әйе.

– Әллә теге зәхмәтне эләктергәнме?

– Шулдыр... Ютәлли, укшый, сулышы каба, жар!..

Нажия телефонына ябышты: "Скорый, скорый, авылда тагын "берәү". Тизрәк килегез! Бөтен авылга таралса – бетте баш!.."

Ничектер, бу юлы "Скорый" авылдан бөтенләй китмәгән шикелле, Нәсимәттиләр капка төбендә тора иде.

Миллерны караватка сузып салдылар да, әйләндерә-әйләндерә карап, кан басымнарын, температурасын үлчәп, авыз эчләрен актарып, борын тишекләренә хәтле кереп, ах-вахына карамыйча, машинага чыгарып яткырдылар. Өйдән Нәсимәттинең: "Улым, улым!" – дигән үзәк өзгеч сүзләре генә яңгырап калыр сыман иде, табиблар кире борылып өйгә керделәр дә, Нәсимәттине култыклап алып, санитар машинасына аны да этеп керттеләр. "Скорый", тузан бөркеп, авылдан үзәккә ыргылды.

Нинди чир булса да үтә ул. Менә монысы да бетеп килә. Ютәл төшеп дәвалансаң – ике атнадан, дәваланмасаң унбиш көннән бетә, диләр. Бу чир белән дә шулай икән. Булништа Миллерның ике яклап үпкә ялкынсынуын тажлы вируска чутлап, әнисенекен дә шуңа сылтап, тагын өйләрендә ике атна карантинда яткырачакларын әйттеләр.

Нәсимәтти көн саен улының хәлен белешеп торды. Берәр медсестра белән танышмады микән?.. Андый яңалыклар юклыгын белгәч, үзе янына килеп дәвалый торган Гүрзүл исемле кызга күз салды.

– Сеңлем, 140 нчы бүлмәдәге Миллер дигән егет минем улым ул. Өйләнмәгән, озакламый институт бетерә. Шуның белән танышсагыз күңелем булыр иде. Син дә бик итагатьле күренәсең. Башлы-күзле түгелсеңдер әле? – дип тә сорарга читенсенмәде.

– Юк, әле, – дип ягымлы гына җавап кайтарды чибәркәй.

"Тавышы да матур, черелдек түгел икән" дигәндәй, куанычын яшермәде Нәсимәтти, аның водолазларныкы сыман су астына төшә торган зур күзлеге артындагы акаеп торган күзләренә карап.

Әни кешенең һәр теләге Аллаһының амин дигән чагына туры килеп барды. Кавыштылар болар. Булачак кайнананың булачак килене йөзен бик тә күрәсе килсә дә, мөмкин түгел иде. Алар бөтенесе бер киемдә – шул күк төстәге махсус формада йөрделәр. Ахрысы, чишенмичә шулай йоклаганнардыр да. Хәрби режимдагы кебек.

Бәхетенә, Нәсимәттине булнистән алданрак чыгардылар. Куанды. Килен каршыласы булыр, өй җыештырасы. Аңа инде алдагы бәхетле тормышның очы күренә иде. Гел җырлап кына йөри башлады. Шатлыгын сердәшләре, авылдашлары белән уртаклашуын әйтәсе дә юк. Такташ әйтмешли: "Башларыннан инде аның коммунизм кыры күренә!.."

Менә яшьләрнең кайтыр көннәре дә җитте. Кай арада бу тантананы сенсациягә әверелдерергә телевидениесе дә килеп җиткән. Нәсимәтти капкасы киң итеп ачылып куелган, җыелган халыкның чиге юк. Бар да матур киенгән.

Ниһаять, малай-шалайның: "Кайталар!" – дигән тавышы урам яңгыратты. "Ларгус" машинасында моңа хәтле җилфердәгән өч шарның берсе исән калып, "туй кайта" төсмеренең чагылышы бар әле. Иң элек арткы ян ишектән Миллер чыгып, җәлт кенә икенче якта утырган киленне чыгармакчы булды. Җил дә юк иде югыйсә, нигәдер, ул чайкалып китеп капотка таянды. Сизделәр. Миллер киткәндәге хәлендә. Ләкин халык каршылау алкышларын туктатмады. Килен "Ларгус"ның икенче ишегеннән үзе чыкты. Авылның бердәнбер сиксән ике яшьлек гармунчысы Гайнемөхәммәт бабай "Туй" көен уйнап җибәрде. Бу хәтле югары дәрәҗәдә каршылауны көтмәгән килен-врач, кызып китеп, моңа хәтле бер мәртәбә дә салмаган водолаз-бака киемен салып ыргытты. "Браво, браво!" – дип, кул чабарга тотындылар телевизорчылар. Ләкин килен кеше башлыгын, күзлеген, битлеген йолкып читкә томыргач, халык "аһ!" итеп куйды. Борын астыннан кара мыек ялтырый иде. "Бәрәч, ир затыннан түгелме соң бу?!" – диеште барысы да. Миллерның аптыраган йөзе, шаккатып ачылган авызы белән капланды. ... һәм басуга таба йөгергәне истә.

Калганын хәтерләмим. Сөйләделәр: Миллер шуннан соң гына эчүен ташлаган. Ярый, тәүбәгә килүгә монысы да ярап тора. Ә менә Нәсимәтти һаман булништа: "Килен, килен!" – дип саташып ята ди. Терелер, әлбәттә. Элеккеге апалар нык алар!

Кая тәгәри бу дөнья?..



Шамил ХӘЛИУЛЛОВ рәсемнәре



МИРЗАҺИТ ТОРМЫШЫННАН

ТОРЕАДОР

Бер көнне кич өйдә утырганда Мирзаһит бик сәер тавышлар ишетте. "Караклар кергән мәллә, – дип уйлады ул, – урларлык бернәрсәм дә юк бит югыйсә". Хатыны белән бергәләп яктыртылмаган өйалдына чыксалар, күзләре шар булды, каршыларында мөгезле әллә нәрсә тора иде. Җитмәсә, тояклары белән шакылдата. "Җен мәллә бу, нишләп монда килгән, минем арттан йөрүедер?.." – дип уйлап куйды ул шул мизгелдә. Хатыны, нишләвең бу дигәндәй, касыгына төртеп алды. Мирзаһит аңына килде – өйалдына кемнеңдер зур гына үгез бозавы кергән икән. Җәлләп тә куярлык үзен, арты белән кире чыгарга җай таба алмый, каршыдагы тәрәзәгә ыргыла. Мирзаһит мескен хайванны коерыгыннан да тартып карады, хатыны да алдында чиләк кагып торды, юк – борыла алмый. Каян аңласын инде боларны – бозау бит ул. Шулчак Мирзаһит моның сыртына атланды, мөгезенә тотынып, муенын чыгу ягына борды. Ишектә сыек кына яктылык күреп, үгез бозау тышка ыргылды, Мирзаһит мәтәлеп тә төште. Моны күреп торган хатыны ахылдарга да өлгерми калды.

– Кайчагында тормышта үгезне дә авызлыклый белергә кирәк, – дип мактанып куйды, авырткан биленә таянып Тореадорыбыз.

КЕНДЕКЛЕ КАНДИДАТ

Сайлау алдыннан авылга бик кыйммәтле костюм-ботинкалар киеп кандидат килде. Халыкны җыйдылар һәм ул, кәгазенә карап, чыгыш ясый башлады.

– Мине сайласагыз, балалар мәйданчыгы да булыр, бөтен шартлары тудырылган мәктәп ишегаллары да һәм яңа койма белән зиратны да әйләндереп алырбыз.

Халык, бу хәтле мәрхәмәтле җанга карап, берберсе белән пышылдаша һәм көлешә үк башладылар. Моның дәртле хәрәкәтләр ясап сөйләвеннән алагаем корсагы янындагы күлмәк төймәсе атылып китте һәм бик зур пилмән төсле кендеге күренде.

Кандидат кәгазьдәге сүзләрне тезүен белде.

– Мин сезгә хәерчелектән котылырга ярдәм итәчәкмен, һәммәгезгә эш булачак! Сезгә бары тик мине сайларга гына кирәк!.. – ул сөйли, ә халык кендегенә карап көлә торды.

– Ә сез үзегез кем булып эшлисез? – дип тавыш салды араларындагы Мирзаһит.

– Әйе, мин... гомер буе... – кандидат кәгазеннән күзен күтәрде һәм көтелмәгәндә: – Минем куллары гел сөялдә, – диде.

– Шулай шул, без сезнең "сөял"не күрәбез, – дип турысын әйтеп салды халык арасындагы тагын бер туры әйтүчесе – Мирзаһит инде. "Безгә мондый "сөял" ясау өчен күп җир сөрергә кирәк!

Кандидат, ул-бу булмагае дип, аңышмый торды да, кулы белән кендеген каплады. Кая монда чәй эчәргә калулар...

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТЕВ

Александр КОСМЫЛИН



Михаил ЛАРИЧЕВ





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

– Юк, кадерлем! Башта – туй, аннан соң гына түшәк!

– Әйдә, чынбарлыкка кайтыйк әле. Хәтта машина сатып алганда да башта эшләтеп карыйсың, шуннан соң гына документлаштыру бит.

• • •

Ир кеше касса янына килә, сатучы ризыкларга чек суга. Һәм:

– Пакет кирәкме? – дип сорый.

– Кирәк, – ди сатып алучы.

– Россия Конституциясенә төзәтмәләр пакетына тавыш биргәнегез өчен рәхмәт, – ди сатучы.

• • •

– Интегеп яшәүче мохтаҗ артистларга 5000 лекне фотога төшереп кая җибәрергә икән?

– Ни өчен фото гына, чынын җибәрегез?

– Соң алар үзләре дә бит җырламый, фонограммага авыз кыймылдатып кына торалар...

• • •

– Беләсезме, – ди директор хезмәткәренә, – эштән беркемнең лә үлгәне юк әле.

– Мин менә беренче корбан булудан куркам да инде.

• • •

– Исәнмесез! Минем кредитка аракы аласым килгән иде.

– Чыраегызның төсенә караганда, кредит тарихыгыз шактый кызыклы булырга тиеш.

• • •

Ике дус ресторанннан чыгып килә.

– Карале, – ди берсе икенчесенә, – син гардеробчыга күп бирмәдеңме? Биш йөз сум артыграк, минемчә.

– Күп дисеңме? Син башта күз сал – ул миңа нинди шәп пальто бирде!

• • •

Бүлек мөдире – хезмәткәренә:

Эшләгәндә сызгырып утыру килешми!

– Ә мин эшләмим. Сызгырам гына.

• • •

Ресторанда.

– Официант, ә хәзер миңа берәр айныта торган әйбер китерегез.

– Рәхим итегез, сезнең счёт!



И хәтер, хәтер...

Евгений ОБУХОВ

И хәтер, хәтер! Гел кәефне кыра бит, дөмеккере. Менә, мәсәлән, күптән түгел кибет каймагы эчеп карадым. Акка кара белән "Майлылыгы 11%» дип язылган. Эчәм һәм сизәм: чынлап та майлы, куе. Нәкъ элекке замандагы дүрт процентлы сөт кебек. Ә хәтер үзенекендә тора, ул чактагы фермадан килгән сөт белән хәзерге каймак арасында бернинди аерма юк ди. Шунда ук кәеф кырылды: хәтер дигәне төптән шушы чагыштыруны тартып чыгарды.

Тагын менә яшелчәләрне алыйк. Үзем турыйм һәм тоям: ни дисәң дә, яшелчә исе килә бит! Ә хәтер искә төшерә башлый: әйе, балачакта чыршыга аса торган пластмасс яшелчәләрдән нәкъ шушы ис килә иде. Әйе, әйе, нәкъ шушы! Димәк, тагын кәеф кырылды. Бөтен ләззәтне бозды бит!

Йә, мәсәлән, экранда тамак яручы йолдызларның йолдызларын тыңлыйсың ди. Хәтерне тынычландырырга телим: берәр нәрсә китереп чыгармагае... Кая ди ул! Ярты минуттан ук совхоздагы үзешчәннәр смотрында җырлаучылар искә төшә. Билләһи, дим, алар шәбрәк җырлый иде бит! Тик җырчыларның артякларыннан төсле каурыйлар тырпаеп тормый иде...

Нәрсә сөйләп торырга – бу хәтер адым саен аяк чалырга чамалый. Берзаман телевизорда программаларны күчереп утырам. Ниндидер бик җитди утырыш трансляциясенә юлыктым. Кемнән һәм күпме кисү турында сөйләшәләр иде. Һәм шунда ук хәтер үзенекен тукый башлады: "Ә элек бит, – дип пышылдый бу, – ни генә дисәң дә, әзрәк халык турында да кайгырталар иде". Әйе, шулай иде шул! Телевидение-газитләрдә дә карак байлар һәм сәхнә "йолдызлары" белән түгел, ә эш кешеләре – комбайнерлар, корыч коючылар, терлекчеләр, укытучылар, төзүчеләр, тәрбиячеләр, тегүчеләр белән сокланалар иде... Тукта, тукта! Нинди сүзләр әйттерәсең син миңа, хәтер? Бүгенге телевизорны карап, мин боларны онытып бетергән идем бит! Кемнәр алар? Нәрсә бу? И хәтер, хәтер, гел кәефне кырып торасың бит!..

Маннур САТТАРОВ (1920–2016)
Бөек Ватан сугышы ветераны

САЙЛАУ ТАКМАКЛАРЫ

Гармун телләре вак-вактыр,
Безнең җырлар такмактыр.
Сайлау алды вәгъдәсенә
Җүләр балык капмактыр.

Тал егыла, тал егыла,
Әллә тамырсыз микән?
Депутат итеп сайласак,
Безне танырсыз микән?

Әйдә, барыйк театрга,
Театр уйнатырга.
Сайлап куйган депутатлар
Әйләнде «сенатор»га.

Киим дисәм бүркем бар,
Биим дисәм күркем бар.
Җаным тарткан кандидатка
Шар салырга иркем бар.

Ишегалдым сары салам,
Җыеп малларга салам.
Исемлектә иске тузлар,
Кабат сайларга калам.

Сайлау участокларының
Фасадлары әләмле.
– Печәнсез калыйм димәсәң,
Сайла, – диләр, – фәләнне!

Өй артында шомыртым,
Яннарында багана.
Законсызлык Закон белән
Санашмаган замана.

Агыйделләрне киң, диләр,
Диңгезләргә тиң, диләр.
Уннан берсе сайласа да,
«Сайлап куйды ил!» – диләр.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәликә.
Ничек сайлау әле бер эш,
Ничек санау хәл итә.

Күрше карчык Галимә
Тавыш биргән Галигә.
Гали җыйган бар тавышны
Теркәгәннәр... Вәлигә!

Биек тауның башларында
Тегермән тарттыралар.
Думалылар үзләренә
Эш хакын арттыралар.

Ак та кисә, күк тә кисә
Тегүче кайчылары.
Ил сыртына ияр салды
Капитал пайчылары.

Борис СТАРЧИКОВ «Чаян» № 4, 1968



– Культуралы кеше белән танышуыма бик шатмын!

Виктор ИГНАТЬЕВ «Чаян» № 4, 1968



– Нигә мөдирегезнең колаклары юк?
– Кирәк булмагач, өзелеп төшкәннәр. Ул һәрвакыт үзе генә сөйли, башкаларны тыңламый да.

КӨЛКЕ КАМЕРАСЫ



СӘГАТЬ ОПЕРАЦИЯСЕ

Казан кибетләренең берсеннән кыйммәтле сәгатьне урлау өчен чын операция планлаштырылган. Мәскәүдән заказ бирелгән 200 мең сумлык затлы әйберне алырга товар бәясен алдан түләп куйган сатып алучы килгән. Паспорт урынына ул сатучыга фото ябыштырылган ниндидер вакытлы белешмә күрсәткән. Сатучы кыз, шикләнмичә, товарны төреп биргән. Ә берникадәр вакыттан соң сәгатьне алырга аның чын хуҗасы килеп җиткән.

Сәгать чәлгән каракны тиз тапканнар – ул Биектауда яшәүче 30 яшьлек ир булып чыккан. Полицейскийларга шунда ук үзенең мошенник корбаны булып чыгуы турында белдергән. Имеш, ул түләүле эш турында белдерү тапкан һәм «эш бирүче»нең күрсәтмәләрен генә үтәгән. Белешмә ясап, сәгатьне алып саткан, акчасын теге биргән счётка күчергән. Ә эш өчен тиеш «хезмәт хакын» алмаган. Бу хикәятнең тормышка нинди дәрәҗәдә туры килүен хәзер тикшерүчеләр ачыклый.

Виктор ФЁДОРОВ



Игорь КИЙКО



Александр БРЮХАНОВ



– Исемең, фамилияң?

– Көчле лампа яктысы урта яшьләрдәге ир затының кырынмаган йөзенә төште ...

– Мин... – дип тотлыга-тотлыга авызын ачты ул һәм куркуыннан җилкәләрен кысып, туктап калды...

– Белемең нинди? Ишетмим!

– Кырыс кыяфәтле бүлмә хуҗасының үткен карашы аны үтәли тишеп үтте.

– Урта... бетерелмәгән урта бугай... Хәтерләмим...

– Нинди мәктәптә укыдың? Әдәбият, физика, арифметикадан кемнәр укытты, чиреккә нинди билгеләр куялар иде? — лампа җавап тотучының йөзенә тагын да якынлашты.

– Хәтерләмим, – диде ул һәм аның бер күзендә яшь тамчысы күренде...

– Синең өчен кем хәтерләр? – сорау алучы йомарланган йодрыкларын өстәл уртасына куйды. – Атаң-анаң кемнәр? Кайда эшләделәр? Кайда яшәделәр?

Икенче күз дә мөлдерәп тулды.

– Дөресен сөйлисеңме?

– Нәрсә сөйләргә?

– Үзең беләсең...

Шул чакта ишектәге ачкыч борылды һәм хатын-кыз тавышы ишетелде:

– Кадерлем, ничек, кранны рәтләдегезме?

– Нинди кран? – дип гаҗәпләнде сорау алучы. – Үзең бит сантехник белән аңлашырга кирәк дидең... Менә, алып килдем, аңлашып утырабыз...

– Ярый әле ипи шүрлеген җимерергә өлгермәгәнсең. Әйдә, кулларын чиш тә, ваннага кертеп җибәр үзен...

– Башта ук шулай диләр аны. Алайса нәрсәдер сөйләргә кушалар, — дип сукранды слесарь һәм яшьле күзләрен сөртеп алды...

Хатын тирән сулап куйды да кухняга юнәлде:

– Полициядә эшләгәнне пенсия генә төзәтми икән шул...





УРЫННАН УРЫНГА

Хөрмәтле редакция! Шәхси йортлар торышын муниципалитет вәкилләре бик карап, тикшереп кенә торалар. Койма янында үскән үлән 20 сантиметрга арта икән – 3000 штраф! Шулай ук өйалдында чүп-чар өелеп торса яисә төзү материаллары җыелып куелса да штрафны көт тә тор. Кеше чүбен күрә болар, ә борын төбендәге үзләренең тау кадәрле чүп өеме күренми.

Берничә ел элек авылдан бераз читтәрәк чүп базы барлыкка килде. Әллә ничә чакрым җиргә сузылган чүплектә нәрсә генә юк, хәтта ниндидер янгын калдыклары да.

Безнең шикаятьләрдән соң Лаеш районы исполком вәкиле әлеге проблема хәл ителде, диде. Ә нәтиҗәдә: бер бульдозер күчерә алганын якындагы чокырга илтеп тондырды да, күмә алмаган чүпне икенче урынга гына күчереп куйды. Безнең йортлар каршында тагын бер чүп өеме пәйда булса да, гаҗәп түгел, чөнки бу өем бер урыннан урынга гына күчеп йөри.

Татар Янтыгы авылында яшәүчеләр.

ЛАЕШ районы

НИШЛӘРГӘ БЕЛМИБЕЗ

Кадерле "Чаян"! Әти-әнисе, замана баласын ничекләр итеп телефон, гаджетлардан аерырга, саф һавада уеннар уйнатырга белми интегә. Ә безнең нефтехимиклар шәһәрендә андый проблема юк. Ләкин башкасы бар...

Бала-чага дөньякүләм Интернет челтәрләреннән арынып, Кояшлы урамындагы төзелеп бетмәгән йортлар тирәсендә чуала башлады. Монда үсмерләр өчен күңел ачу мөмкинлекләре компьютер уеннарындагылардан күбрәктер. Кечерәк яшьтәге балалар "штаб" төзеп уйнаса, яшүсмерләрнең башка шөгыль – ул да булса пыяла ватып, спиртлы эчемлекләр эчеп, түбәдә дискотека оештырып, яндыра алган барлык нәрсәгә ут төртү...

Әлеге тәртипсезлекләргә "Гейм овер" гына күренми. Бу озакка сузылган төзелеш шәхси булганлыктан, аның сакчылары да юк, аның кайчан бетәсе дә билгесез. Якын-тирәдә яшәгән, тавыштан туйган халык әлеге балачагаларны өйләренә – гаджетларга куып кайтарырга мәҗбүр. Башка чара калмый...

В. ВИЛДАНОВ

ТҮБӘН КАМА



Валерий ТАРАСЕНКО



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Вячеслав ШИЛОВ

Дамир МОРТАЗИН



Рәхәт тә инде телевизордан "юл сугышлары" карап ятуы. Андагы кызыкларны күрсәгез! Гаишникларга эш чыгып кына тора. Йә ирегетләр резин күсәкләрен селтәшә, әйтерсең, әкият паһлеваннары... Йә автоханымнар бер-берсенең чәченнән тартыша, шулай итеп кемнең дөрес, кемнең гаепле икәнен белеп була микәнни... Берниндди әдәп дигән нәрсә юк инде – хәтта КАСКО белән ОСАГО да талашучыларның һәм сугыш чукмарларының исенә дә кереп чыкмый...

Шулай да менә шундый хәлиткеч минутларда да башын югалтмаган, зыялы һәм әдәпле кешеләр очраштыргалый. Менә мин бер тапкыр үзем күреп тордым андый очракны. Ягъни шаһиты булдым...

Юллар кисешкән урында джип "Лада"ны җимерде. Җәяүлеләр шундук бу аварияне тикшерергә тотындылар.

– Берсүзсез джип гаепле, ул үткәреп җибәрергә тиеш иде... – дип хөкем чыгарды берәү – күрәсең, белмәгән нәрсәсе юк.

– Ай-яй, шәп арбасы! – диде өлкәнрәк яшьтәге абзый. – Байтак урлаган инде бу... Мондыйлар беркайчан да гаепле булмыйлар – бөтен судны сатып алачак...

– Дөрес әйтәсең! – дип сүзгә кушылды шактый таза апа. – Правасын да сатып алгандыр, йөртә дә белми икән бит!

– Менә хәзер карагыз, иң кызыгы башлана! – дип боларның сөйләшүен бүлде тишек-тошыклы джинсы кигән яшүсмер егет. Югыйсә күзәтүләреннән чыккан фикерләре үтә актуаль – социаль тигезсезлек турында иде.

Джиптан кулларын йодрыклаган, ачудан чыраен җимергән төс ясап, буе да иңе дә бер үлчәмдә булган егет чыкты. Ныклы адымнар белән "Лада"га таба атлады.

– Манчый бу тегене хәзер! – диде яшүсмер, алдан ук белгән кебек.

– Кызганыч мескенкәй... – дип ухылдап куйдылар карап торучылар.

Ләкин якынрак килгән саен, джип хуҗасының йөзе үзгәрә башлады. "Лада"ның ачык тәрәзәсенә ул инде гаепле елмаю чыгарып карады.

– Зинһар өчен, гафу итегез! – дип тотлыгыбрак әйтте сүзен. – Минем белән мондый хәл беренче мәртәбә... Гаеп миндә... Борчылмагыз – ДТП схемасын үзем сызам һәм ЮХИДИга илтәм... Расходларны каплыйм...

"Менә, – дип уйладым мин, – итагатьле машина йөртүче, күпләргә үрнәк... Бик тә зыялы булып чыкты бит әле бу, карап торышка һич уйламассың..."

– Ә "Лада"да кем утыра соң? – диеште вакыйганың болай борылышына аптыраган халык.

Аңлашу тиз булды. Белмәгән нәрсәсе булмаган әлеге дә баягы кеше, җимерек машина кабинасында утыручыга текәлеп караганнан соң әйтеп куйды:

– Бу – безнең прокурорның хезмәтендәге машина. Ә руль артында – ул үзе...

– Прокурор? – дип шикләнеп шаулашып алды кешеләр. – Шушындый машинадамы?

– Бюджет чараларына экономия компаниясе башланган иде аларда, – дигән сүзләр белән белдекләнеп әйтеп куйды тагын теге күп белүче кеше. – Ә үзенең ике джибы коттеджының гаражында тора...

"Кара инде! Икенче машина йөртүче дә зыялы һәм бик әдәпле икән... Прокурор булса да..." дип уйладым да "юл сугышлары"н карарга өйгә кайтып киттем.

Игорь КИЙКО



СОҢЫННАН НӘРСӘ БУЛГАН...

«Чаян»ның 5 нче санында «Салават күпере» торак комплексында яшәүчеләрнең хаты басылып чыккан иде. Инде ничәнче ел кышын мондагы йөзләгән фатирларда җил уйнап тора. Хат авторлары фикеренчә, моның сәбәбе яңа технология буенча эшләнгән стена блокларының «утыруыннан» булуы мөмкин.

Безнең чыгыштан соң бу мәсьәлә белән ТР Президенты каршындагы дәүләт торак фонды шөгыльләнә башлаган. Анда июнь ахырына кадәр «Салават күпере»нең 350 фатирында бу җитешсезлекләр бетереләчәк. Блоклар арасындагы җөйләр герметизацияләнәчәк. Төзекләндерү эшләре фатирларның эчендә дә, тышкы якта да үткәреләчәк. Секцияләр арасындагы деформация җөйләрен ныгыту да каралган.

ФИКЕРЛӘР ТУПЛАНМАСЫ

Рөстәм ЗАРИПОВ

ТЕЛӘК

Сиңа күршең йөз ел гомер теләдеме?
Ә күршең бит сине каргаган...

Алишер Нәваи

...Мин ул затка йөз ел гомер телим. Юк, йөз ел аз, мең ел яшәсен. Илне талаганын хаптыр-хоптыр, рәхәтләнеп мең ел ашасын... Балалары мең ел гомер сөрсен, оныклары мең ел күшәсен, әйдә, сыптырсыннар бер утырудә, дүрт аяклы маллар түшкәсен... Андый "уңышлыларның" артыгы, ул бит мазлумнәрнең актыгы... Еллар узган саен өскә чыга Тукай дәреслеге, хаклыгы.

Мин ул затка йөз ел гомер телим. Юк, йөз ел аз, мең ел яшәсен. Күбенгәнче эчеп мескеннәрнең күз яшьләре тулы кәсәсен...

КИСКЕН ҮЗГӘРЕШ

Бул минеке генә, юкса бетәм! Үлә-бетә сине генә телим! Үлсәм үләм, башкаларга бирмим! Сине генә даулый минем күңел, синнән башка мин бит беркем түгел, сине генә аулый минем күңел, ки дә камыт, арбабызга җигел...

Әтрәгәләм шагыйрь шулай сырлый. Моңнан мәхрүм җырчы шулай җырлый... Рухи хәерчеләр эчтән елый, шундый чүп-чарларны тыңлыйтыңлый...

Ә бит ихлас гашыйк андый булмый! Сөйгәнен шәхси милек дип тоймый... Аңа шартлар һәм таләпләр куймый, тик аның хагын хаклауны уйлый...

...Онытылмый бер борынгы кыйсса, ахыры тетрәтә, чыкмый истән, гадәти бер сөю өчпочмагы: сылу кыз һәм ике егет тагын... Сөйгәнем, дип, берсе төшә суга, бергенәм, дип керә янган утка, үз күкрәген куя ахыр чутта, көндәшенә кемдер аткан укка... Кыз инрәвенә каршы шул егет, соңгы сулышында телгә килеп:

– Син бәхетсез булыр идең ансыз, – дип әйтә дә тынып кала җансыз...

Замандаш әдипләр иҗатында – кытлык, адәм рәтле ир затына. Геройлары үзләре күк мүкләк, укыса кем, интегәчәк үтләп...

ТУҢ ТОМНАР

Телебездән, җырыбыздан югала моң, сүзләрдән нур кача, иңә күңелгә шом. Әдипләребез артыннан коела ком. Күрче, чыгарып яталар том арты том... Томнар гына кибет киштәләрен күрми, аларда ни язылганын һичкем белми... Китапханәләр шул малдан шыплап тулган, чекерәеп тора алар уңнан, сулдан. Бу тәртипне кем кануный уңайлады?.. Әлбәттә, милләтнең шомбайлары!..

Җәбер, золым изгән җанны моң дәвалый бары, татар яши алмаячак җырларыннан ары... Татар яши алмаячак, моңнарыннан язса, юкны-барны җыр дип белеп ялгышса, саташса... Сораулар күп, җавабын тик вакыт әйтеп бирер, милләтебез әле беркөн акбүз атта җилер... Акбүз атта җырлап килер "Туган ягым" җырын, киләчәккә илтеп безнең күңелләрнең нурын!..

ЯРЫЙ ӘЛЕ ШАГЫЙРЬ ТҮГЕЛМЕН

Илһам кабып, кулга каләм алгач,
Чуалыша уйлар, фикерләр.
Хиссез кеше моны аңлый алмас –
Иҗат итә шулай шагыйрьләр.

Иҗат итү, язу – ул ярты эш,
Дөрләсә дә ярсу йөрәкләр...
Китап чыгу һәм союзга керү –
Бусы сорый акча көрәкләп.

Союзы да Олимп түгел әле,
Ярамыйдыр арып аварга –
Кешелеккә әгәр чыгам дисәң,
"Йонлы куллар" кирәк табарга.

Зур шагыйрьлек яңа үрләр сорый! –
Ирешәсе – җанны телгәли.
Үрләр эзләп, күпләр Тукай торган
Пьедесталга таба үрмәли...

...Бу нәрсәдә берни аңламыймын –
Дан-шөһрәткә һич тә үрелмим.
Рәхәтләнеп өйдә шигырь язам –
Ярый әле, шагыйрь түгел мин...

ОЧАМ...

Очам...Очам...
Кая очам – белмим...
Артка, алга, уңга, сулгамы...
Әллә күккә – биеклеккә ашам,
Әллә аска – төпкә убаммы?..
Кайсы якка – мин битараф моңа,
Иң мөһиме – шушы халәтем.
Ләззәт бирә миңа онытылып,
Иркен сулап очу сәләтем.
Чын ирекне тою мөмкинлеге
Бүләк иткән Ходай адәмгә.
Шуңа күрә "ас-өс" төшенчәсен
Кертмәгән ул чиксез Галәмдә...

Ринат АБЗАЛОВ



САТИРА ҺӘМ
ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.

№ 7 (1896) июль 2020

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpişka.pochta.ru онлайн аша
языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.


«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 2.07.2020 ел.
Тираж –1353 Заказ А-1492

**Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.**

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!





1. Нәрсә ул алкоголь?

2. Хәерчелек ярлылыктан нәрсәсе белән аерыла?

3. Елга ике мәртәбә була торган бик кыен көннәр кемдә?

4. "Активиа"га караганда организмны яхшырак чистартучы әйбер.

5. Кем ул ир?

6. Начар абруй нәрсә ул?

7. Үбешүне кем уйлап тапкан?

ҖАВАПЛАР

1. Чын тормышны "матурлап" күрсәтүче көзге. 2. Хәерчелек – хәер сорану, ярлылык – хәтта хәер дә бирә алмау. 3. Студентларда. 4. Селёдкада тотылган сөт. 5. Хатын-кыз тарафыннан куелган капкыннарга таба торган аучы. 6. Башкалар теләгәнчә яши белмәү. 7. Хатын-кызны эндәштермәс өчен ир-атлар уйлап чыгарган ысул.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Ринат АБЗАЛОВ төзеде

Чайнвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 6 нчы санында басылган чайнвордның тикшерү сүзе – **«ГАРМУН АЛЫЙК ӘЛЕ, ДУСКАЙ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Г. ГЫЙМАЛТДИНОВА (Нурлат р-ны, Киекле ав.),
Ш. ДӘҮЛӘТШИН (Казан),
В. СУХАНОВА (Чаллы),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан),
Р. САФИН (Балык Бистәсе р-ны, Полянка ав.),
Г. ХАННАНОВ (Томск өлкәсе, Бакчар р-ны, Вавиловка ав).

Җиңүчебез – Казаннан

Шамил ДӘҮЛӘТШИН!




Светлана **ФӘТТАХОВА**га бу көннәрдә 60 яшь тулган булыр иде. Кызганыч, бу чибәр, гүзәл җанлы һәм талантлы ханым берничә ел инде арабызда юк. Иҗади гомеренең зур өлешен ул укучыларыбызны шатландырып, «Чаян» белән хезмәттәшлек итте. Аның рәсемнәре үзенчәлекле – башкару техникасы һәм ачык төсләр белән аерылып тора иде. Бу вернисаж да рәссам Светлана Фәттахованы искә алу итеп кабул ителсен.





– Сезнең «әтәч»ләрегезне кош кизүенә тикшерү артык булмас иде!



– Нигә стриптиз белән шөгыльләнергә булдыгыз?
– Ач һәм ялангач йөрүдән туйдым!

